БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 09 2024 ел № 231

2025 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны ташуны оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1.Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2025 елга бәяләре нормативлары;
- балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе нормативлары нигезендә финанслау.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024 елның "20" 09
231 номерлы карары белән
расланган

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2025 елга бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сумнарда | автотранспорт чарасының бер километрга йөгерү ставкасы, елына сумнарда |
| КАВЗ | 1 128 838,81 | 24,40 |
| ПАЗ | 1 129 096,31 | 24,56 |
| ГАЗ «Газель» | 1 107 926,16 | 15,73 |
| УАЗ | 1 107 472,96 | 14,08 |
| FIAT | 1 110 820,46 | 11,88 |
| Peugeot Boxer | 1 115 970,46 | 11,47 |
| Ford Transit | 1 116 227,96 | 16,08 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 131 053,31 | 21,60 |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2024елның "20" 09
231 номерлы карары белән
расланган

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучылар йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативлары ел саен Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында факттагы узган юлы буларак кабул ителә.

## 2.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны ташуны оештыру бәясенең нормасы бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны йөртүне оештыру бәясе нормативының бер автотранспорт чарасына ставкасы,сумнарда;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.